# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**23 ноябрь 2022 ел** **№1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сөендек авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Уставы нигезендә 2022елның 23 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

“Сез 2023 елда Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 1500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 750 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәтенә түләү, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр сатып алу, янгын депосын агымдагы ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу);
- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге (Сөендек авылы Кооператив урамы буенча юл участогын ремонтлау);
- Бәйрәм чараларын оештыру өчен шартлар тудыру һәм бәйрәм чараларын уздыру ("Җиңү көне", "Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне", "Инвалидлар декадасы", "Яңа ел" бәйрәмнәренә бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу, милли бәйрәмнәр өчен реквизитлар алу (яңа ел чаналары, Сабантуй өчен арба), чараларны уздыру өчен аппаратура һәм инвентарь алу (4*8 м ябык павильон, рамлы түбә));
- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру (Сөендек авылы мәдәният йорты өчен урам бәдрәфе сатып алу, чүплекләрне рекультивацияләү, балалар өчен уен аттракционнары һәм спорт инвентаре сатып алу, үләнне механикалаштырылган чабу һәм триммер сатып алу, Сабантуй мәйданын төзекләндерү (капка, койма кую, сәхнә урнаштыру, багананы алыштыру, утыру урыннары ясау, бакча бәдрәфе сатып алу), МТЗ-82 өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (көрәк, сәнәк, КУН-10, щетка) һәм булган җиһазлар өчен (чапкыч, отвал) запас частьләре сатып алу, Сөендек авылы мәдәнят йортына кул насосы белән скважина урнаштыру, Сөендек авылында мәдәният йортын һәм башлангыч мәктәпне коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу, юлларны кардан чистарту);

- Сөендек авылы зиратларын карап тоту (8 куб. м ябык бункер алу, койма белән 3*4 контейнер мәйданчыклары урнаштыру, зиратларны чистарту)?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 106 граждан теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны - 74 .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 74, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пунктында гражданнар җыенын узган дип табарга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2023 елда Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 1500 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 750 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәтенә түләү, ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр сатып алу, янгын депосын агымдагы ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу);

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге (Сөендек авылы Кооператив урамы буенча юл участогын ремонтлау);

- Бәйрәм чараларын оештыру өчен шартлар тудыру һәм бәйрәм чараларын уздыру ("Җиңү көне", "Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне", "Инвалидлар декадасы", "Яңа ел" бәйрәмнәренә бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу, милли бәйрәмнәр өчен реквизитлар алу (яңа ел чаналары, Сабантуй өчен арба), чараларны уздыру өчен аппаратура һәм инвентарь алу (4*8 м ябык павильон, рамлы түбә));

- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру (Сөендек авылы мәдәният йорты өчен урам бәдрәфе сатып алу, чүплекләрне рекультивацияләү, балалар өчен уен аттракционнары һәм спорт инвентаре сатып алу, үләнне механикалаштырылган чабу һәм триммер сатып алу, Сабантуй мәйданын төзекләндерү (капка, койма кую, сәхнә урнаштыру, багананы алыштыру, утыру урыннары ясау, бакча бәдрәфе сатып алу), МТЗ-82 өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (көрәк, сәнәк, КУН-10, щетка) һәм булган җиһазлар өчен (чапкыч, отвал) запас частьләре сатып алу, Сөендек авылы мәдәнят йортына кул насосы белән скважина урнаштыру, Сөендек авылында мәдәният йортын һәм башлангыч мәктәпне коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу, юлларны кардан чистарту);

- Сөендек авылы зиратларын карап тоту (8 куб. м ябык бункер алу, койма белән 3*4 контейнер мәйданчыклары урнаштыру, зиратларны чистарту).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

(http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халыкҗыеныдарәислекитүче,
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хаҗиев